| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БАВЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

07.11.2024 ел Баулы шәһәре № 153

Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2011 елның 22 июнендәге 134 номерлы «Хезмәт хакы Бердәм тариф челтәре нигезендә исәпләнә торган Баулы муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт хакын арттыру турында» карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 елның 5 сентябрендәге 731 номерлы «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 елның 14 июнендәге 477 номерлы «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләрендә хезмәт хакы Бердәм тариф челтәре нигезендә исәпләнә торган хезмәткәрләрнең хезмәт хакын арттыру турында» карарына үзгәрешләр кертү турында» карары нигезендә, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2011 елның 22 июнендәге 134 номерлы «Хезмәт хакы Бердәм тариф челтәре нигезендә исәпләнә торган Баулы муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт хакын арттыру турында» (Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2012 елның 10 декабрендәге 281 номерлы, 2013 елның 24 октябрендәге 252 номерлы, 2014 елның 22 гыйнварындагы 18 номерлы, 2014 елның 31 октябрендәге 330 номерлы, 2015 елның 20 ноябрендәге 319 номерлы, 2016 елның 8 июлендәге 219номерлы, 2017 елның 10 августындагы 350 номерлы, 2018 елның 15 гыйнварындагы 11 номерлы, 2021 елның 6 декабрендәге 213 номерлы, 2022 елның 30 декабрендәге 282 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1 пунктның беренче абзацында «2018 елның 1 июленнән» сүзләрен алып ташларга;

күрсәтелгән карарга 1-нче номерлы кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (бирелә).

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының социаль мәсьәләләр буенча беренче урынбасарны йөкләтергә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Л. Бакиров

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесенең
2011 елның 22 июнендәге 134 номерлы
карарына 1-нче номерлы кушымта
(Баулы муниципаль районы
Башкарма комитетының
2024 елның 7 ноябрендәге 153 номерлы
карары редакциясендә)

Баулы муниципаль районы бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт хакы түләү буенча
Бердәм тариф челтәренең тариф
коэффициентлары һәм тариф ставкалары (окладлары)

| Бердәм тариф челтәренең түләү разрядлары | Тариф коэффициентлары | Тариф ставкалары (окладлар), сумнарда |
|---|---|---|
| 1 | 1,0 | 21 200 |
| 2 | 1,0114 | 21 442 |
| 3 | 1,0233 | 21 694 |
| 4 | 1,0346 | 21 934 |
| 5 | 1,0473 | 22 203 |
| 6 | 1,0595 | 22 461 |
| 7 | 1,0728 | 22 743 |
| 8 | 1,0855 | 23 013 |
| 9 | 1,0983 | 23 284 |
| 10 | 1,1119 | 23 572 |
| 11 | 1,1251 | 23 852 |
| 12 | 1,1393 | 24 153 |
| 13 | 1,1535 | 24 454 |
| 14 | 1,1675 | 24 751 |

| | | |
|---|---|---|
| 15 | 1,1823 | 25 065 |
| 16 | 1,1973 | 25 383 |
| 17 | 1,2124 | 25 703 |
| 18 | 1,2280 | 26 034 |

Искәрмә: җитәкче урынбасарының тариф ставкасы (окладлы) күләме тиешле җитәкченең тариф ставкасыннан (окладлы) 1 – 2 разрядка түбәнрәк билгеләнә.